**ГЛАВА АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 22 нче йорт
Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 5 октябре

№1

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы урынбасары

КАРАР БИРӘ:

1. М.Җәлил урамы буенча 12 нчы йорт янында 2023 елның 20 октябрендә 8.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Нариман урамы буенча 10 нчы йорт янында 2023 елның 20 октябрендә 9.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Акъяр Мәдәният йортында (Совет урамы, 20 нче йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2023 елның 20 октябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Акъяр авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
5. Гражданнар Җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2024 нче елга, 600 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар; тыл хезмәтчәннәре ; Россия Кораллы Көчләренең хәрби хезмәткәрләре контракт буенча хәрби хезмәт күрсәтүчеләр, мобилизацияләнүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларын; хәрби сугыш ветераннары; 1 нче төркем инвалидлар; 85 яшьтән узган гражданнар азат ителә һәм үзара салым түләүдән җыелган акчалар түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су башняларын, коеларны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итү, аны чистарту, резидентларны су белән тәэмин итү;

- халык яшәгән район чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын тәртипкә китерү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү;

“ӘЙЕ” “ЮК”.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуцион челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ ,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авылы, Советская ур., 22 мәгълүмат стендында гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча.

8. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы урынбасары Н.Р.Давлетшин